

Боек классик якташ шагыйребез Мо-хәммәтһади Хайрулла улы Такташевны, ягъни Һади Такташны белмәгән кеше бик аздыр; ботен донья белә, анын ижаты торле тел-ләргә тәржемә ителгән. Ул безнен бvгенге Торбеево районы Сыркы-ды - Сургодь авылында туып vскән. Якташыбызны хәтерлибезме икән?

Сыркыдыда анын исеме мәнгеләште-релгән: Һади Такташ урамы бар, бу авылдагы колхоз анын исемен йорткән, музее эшләп килә. Ә регионыбызда анын «Мокамай»ын яттан сойләvчеләр калдымы, бу шигырьне укучы бармы?   Рабит Батулла да Габдрахман Минский авызыннан 1981нче елда ишеткәннәрен болай язып куя: «Һади Такташ кечкенә-дән шаян холыклы, жор сvзле булып vсә. Ул һәр вакыйгага vзенчә такмак-шигырь чыгара торган була. Анын балачак дусты Мокамай-Мохәммәтжан кvкәй урлап тотылгач, кечкенә Һадиулла мондый жыр чыгара: «Дыр-дыр, дырабан, Мокамай кvкәй урлаган; Әйшә тәтәй тоткан, каравылын кычкырткан!»

Еллар уза. Һади Такташ даһи шагыйрь була. Мокамай да Мохәммәтжан булып vсеп житә. Шулчак авылда берәvсенен арба тәгәрмәче югала. Тәгәрмәчне Мокамайга сылтыйлар. Мохәммәтжанны, каты кыйнап, карангы базга ябып ач тоталар. Мохәммәтжан, бу кимсетvләргә, бу гарьлеккә тvзә алмыйча, базда vз пәкесе белән vзен суеп vтерә. Такташ бу фажигане бик авыр кичерә һәм «Мокамай» шигырен яза. Такташ бу шигырен сәхнәдән укыганда, халык vксеп елый, бәгырьләре озгәләнvдән кешеләр:

- Һади абый, тукта, житте! - дип ялвара торган булалар.»

Барысы турында уйлаганыгыз булгандыр, булмаса – тvбәндә, кабат «Мокамай» шигырен укып уйланырга момкинчелек бар.

Мокамай
Белмим,
Әллә кvпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәнге онта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...
Алар мәнге минем хыялымда
Шаулый-шаулый яфрак ярырлар,
Карт имәннәр, калмый минем арттан,
Кая барсам, озатып барырлар...
Бер жирдә юк андый урманнар,

Бер жирдә юк камыш сабаклары –
Андагыдай шаулый торганнар...
Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына vрмәләп,
Ике штансыз малай донья белән
Танышып йоргән идек бергәләп...
Беребез сары чәчле, беребез – кара:
Сары чәчлесе – ул мин идем;
Кара чәчле, конгырт кара кvзле,
Кәкре аяклы дустым, жанкисәгем,
Ул, Мокамай бәгърем, син иден...
Ак каенга аслып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен жирнен матурлыгын,
Яктылыгын кvбрәк кvралдым...
Ә син менәдмәден,
Калдын,
Югалдын...
Әкияттәге ике бала кебек –
Икебез дә кара борынлы,
Зурлар кебек, кулны артка куеп,
Йори идек таптап болынны...
Һәрбер нәрсә безгә яна иде,
Һәрнәрсәгә исебез китә иде,
Бернәрсә дә бездән качмый иде,
Бар нәрсәгә кулыбыз житә иде...
Кvпме кыен кvрдек шунын очен,
Кvпме тал чыбыгы ашадык;
Әкияттәге ике бала кебек,
Кvпме “жафа чигеп” яшәдек...
Кем уйлаган шушы шаярулар
Синдә кәсеп булып калыр дип,
Уйнап башланган эш тормышыннны
Һәлакәткә алып барыр дип...
Хат язсам да хәзер сонга калдым,
Укымассын минем хатымны,
Ләкин минем бурчым, Мохәммәтжан,
Йолу синен яман атынны!
Син гомеренне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләден...
Әллә ничек булды синен гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләден!..
Әкияттәге ике бала кебек,
Каен башларына vрмәләп,
Ике штансыз малай донья белән

Танышып йоргән идек бергәләп...
Ак каенга аслып менгән кебек,
Мин тормышта һаман яктыга,
Югарыга табан юл алдым;
Менгән саен жирнен матурлыгын,
Яктылыгын кvбрәк кvралдым...
Ә син менәлмәден...
Калдын, югалдын...
Үткәннәрем авыр әкият минем, -
Ул әкиятне әгәр сойләгәндә,
Чаглып китсә синен кvләгән,
Юк, юк,
Мин ант итәм: һичбер вакытта да
Сине карак итеп сойләмәм...
Син яшәргә хаклы кеше иден,
Син яшәргә жирдә теләден.
Тик син ачлык тырнагыннан,
Тvбәнлектән
Чыгу юлын гына белмәден...
Ә бит
Бергә чабаталар vреп йоргән чакта,
Син остарак миннән vрәйден,
Минем матур итеп vрәлмәvне
Булдыксызлыгымнан кvрәйден...
Ник сон бу болай булды әле,
Ничек һәлакәтен кvрмәден,
Ник, Мокамай, сон син тормышынны
Чабатандай матур vрмәден!!.
Син гомеренне усал исем белән,
Канлы пычак белән чикләден;
Әллә ничек булды синен гомер,
Син, Мокамай, әллә нишләден!..
Ә бит безнен гомер матур урманнарда
Май аедай матур башланды;
Әкияттәге ике бала кебек,
Икебез ике якка ташланды...
Синен тормыш авыр әкият булды,
Ул әкиятен сонгы битләрен
Син зур исем, мәнге онытылмаслык
Эшләр белән бизәп китмәден...
Син адаштын,
Ләкин син яхшы иден,
Синен яхшы иде кvнелен,
Тик белмәден тормыш баткагыннан
Ялгыз чыгу момкин тvгелен...
Син белмәден,

Кешеләр жирдә тормыш баткагыннан
Чыгу юлын бергә эзлиләр;
Ялгыз калып, ачтан vлмәс очен
Кvмәк тормыш жирдә тозиләр...
Үткәнемне әкият итеп сойләгәндә,
Чаглып китсә синен кvләгән,
Юк, Мокамай, һичбер вакытта да
Сине усал итеп сойләмәм...
Син ярлы иден, ләкин эш соя иден,
Синен яхшы иде кvнелен, -
Син белмәден сыйнфый болгенлектән
Алай чыгу момкин тvгелен...